ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 412-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, Х.Г. Миргалимов, М.Ф. Сыровацкий, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 412-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1891-VI ДС

412-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
Х.Г. Миргалимов,
М.Ф. Сыровацкий,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^4$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^4$ статья. **Депутатларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) хакында гомумиләштерелгән мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе**

1. Комиссия ел саен 20 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру өчен гомумиләштерелгән белешмәләр җибәрә, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:
1) сайланган депутатлар саны;

2) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр тапшыру бурычын үтәгән депутатлар саны;

3) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр тапшыру бурычын тиешенчә үтәмәгән депутатлар саны.

2. Депутатларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) хакында гомумиләштерелгән мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтына урнаштыру Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан Комиссиядән шундый мәгълүмат кергән көннән алып җиде көн эчендә башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләре әлеге Татарстан Республикасы Законы нигезендә үз бурычларын башкарганда үзләренә билгеле булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.»;

2) 13 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында депутат гарызнамә белән Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелеп яисә сайланып куела торган башка органнарның вазыйфаи затларына (Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына аларның компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) законнарны Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә туры китерүгә юнәлдерелгән («Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә).

Закон проекты тарафыннан депутат эшчәнлеге гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында утырышларында мөрәҗәгать итәргә хокуклы затларның (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләре) исемлеге киңәйтелә.

Моннан тыш, закон проектында «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 6 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре дә исәпкә алына.

Аерым алганда, алар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе раслана. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында гомумиләштерелгән белешмәләрдә (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган персональ белешмәләр һәм тиешле затка караган милекне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган белешмәләр булмау шарты белән) түбәндәгеләрне күрсәтү карала:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саны;

2) керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары саны;

3) керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру бурычын тиешенчә үтәмәгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары саны.

Закон проектында шулай ук өстәмә норма беркетелә, аның нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшыру бурычы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан тәэмин ителә.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен киметүгә китерми һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.